**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«11» июль 2024ел № 84

Мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларын комплекслы тикшерү комиссиясе төзү турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге»нең 2023 елның 26 июнендәге 258 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 3 августындагы 615 номерлы «Мәктәп автобус маршрутын ачу турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, автомобиль юлларын (урамнарны) һәм ясалма юл корылмаларын карап тоту дәрәҗәсенең укучыларны мәктәп автобусларында илткәндә юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килүен бәяләү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районында мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларын комплекслы тикшерү комиссиясе төзергә һәм аның составын 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.
2. Комиссиягә Теләче муниципаль районында мәктәп автобуслары хәрәкәтенең 2 номерлы кушымтасында күрсәтелгән маршрутларны комплекслы тикшерергә.
3. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына мәктәп автобусларының хәрәкәт итү маршрутларын комплекслы тикшерүдә катнашырга тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«11» 07 2024 № 84
карарына 1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларын комплексны тикшерү комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Кәримуллин И.Х. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе ЮХИДИ бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Низамов Б.М. | - | район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Карпова Н.В. | - | МКУ «Район Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» башлыгы; |
| Мусин И.М. | - | ДКУ «Главтатдортранс» баш белгече; |
| Ярмиев И.З. | - | «Татавтодор» ААҖ Арча филиалының Теләче участогы башлыгы (килешү буенча); |
| Закиров Г.З. | - | МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» башлыгы вазыйфаларын башкаручы. |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«11» 07 2024 № 84
карарына 2 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутлары

| № т/б | Маршрут исеме |
|---|---|
| 1. | «Теләче – Тәмте Мәтәскә – Ямбулат – Олы Мәтәскә УГББМ – Күкчә – Балыклы – Алан УГББМ» |
| 2. | «Теләче – Лесной – Югары Мәтәскә – Олы Мәтәскә УГББМ» |
| 3. | «Олы Нырсы – Иске Карабаян – Олы Нырсы УГББМ – Кече Мирәтәк – Олы Нырсы УГББМ» |
| 4. | «Теләче – Баландыш – Олы Тиләҗе – Иске Җөри УГББМ – Яңа Җөри – Иске Җөри УГББМ» |
| 5. | «Олы Мишә УГББМ – Баландыш – Урта Мишә – Олы Мишә УГББМ – Олы Саурыш – Түбән Саурыш – Олы Мишә УГББМ» |
| 6. | «Олы Нырсы – Субаш – Айдар – Олы Нырсы УГББМ» |
| 7. | «Теләче – Сауш – Шармаш ТББМ – Алга – Үзәк УГББМ – Караширмә – Үзәк УГББМ» |
| 8. | «Теләче – Төрек-Тәмте – Казаклар – Теләче УГББМ – Теләче (Магистральная урамы) – Теләче УГББМ» |
| 9. | «Теләче – Олы Кибәхуҗа – Югары Кибәхуҗа УГББМ – Максабаш – Югары Кибәхуҗа УГББМ» |
| 10. | «Шәдке – Олы Мирәтәк – Шәдке УГББМ» |
| 11. | «Теләче – Иске Җөри – Үзәк – Орымширмә – Теләче УГББМ – Ачы – Теләче УГББМ» |